**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районы**
**«Иске Кади авыл җирлеге»**
**муниципаль берәмлеге**
**гражданнары җыены**
**КАРАРЫ**

2024 елда Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Иске Кади авыл җирлеге составына керүче Иске Кади торак пунктында үзара салым кертү турында

**26.10.2023 ел** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Иске Кади авыл җирлегенең Иске Кади торак пунктында гражданнар җыены КАРАР КЫЛДЫ:

1. 2024 елда Чирмешән муниципаль районы Иске Кади авыл җирлегенең Иске Кади торак пункты территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 600 сум күләмендә үзара салым кертергә I төркем инвалидлардан, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүчеләрдән, Луганск халык республикасы һәм Донецк халык республикасы махсус операциясендә булган затлардан, 90 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге кешеләрдән тыш һәм алынган чараларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтергә:

- Иске Кади, Якты Тау, Тукай, Светлогорский торак пунктларында урам утларын монтажлау, кую, ремонтлау, карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү, урам утларына кулланган электр энергиясе өчен чыгымнарны түләү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу, баганалар урнаштыру;
- Җәйге һәм кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны төзекләндерү, карап тоту, хезмәт күрсәтү (юл кырыйларын чабу, юлларны грейдерлау, урамнарны кышкы чорда кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары сатып алу, хезмәтләр өчен түләү, запас частьләр сатып алу), югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу чыгымнары;
- авыл җирлегендә чишмә территорияләренең санитар-саклау зоналарын төзекләндерү һәм карап тоту, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу;.
- җәйге чорда урамнарны карап тотуга (триммер белән чүп үләннәрен, юл кырыйларын чабу, ягулык-майлау материалларын һәм

югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материалларны сатып алу);

- Иске Кади авыл җирлеге территориясендә язгы ташудан соң сулыкка таба янгынга каршы юлларны торгызу;

- Иске Кади, Якты Тау торак пунктларында урам-юл челтәрен төзекләндерү (20-40 мм фракциядәге вак таш сатып алу), югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу.

- Иске Кади, Якты Тау, Тукай һәм Светлогорский торак пунктларында янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү (янгын вакытында хәбәр итү системасын сатып алу һәм урнаштыру, сулыкларның һәм янгын гидрантларының күрсәткечләрен сатып алу һәм урнаштыру, янгын гидрантларын сатып алу һәм урнаштыру, ягулык-майлау материаллары, янгын сүндерү машинасы өчен запас частьләр сатып алу, хезмәтләр өчен түләү).

- Иске Кади авылындагы зиратларны тотып алу өчен төзелеш материаллары сатып алу.

- 1 метр диаметрындагы сү үткәрүче труба сатып алу.

2. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Иске Кади авыл җирлегенең рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче
ТР Чирмешән муниципаль районы
Иске Кади авыл җирлеге башлыгы Н.В.Мөктәсимов